ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.06.2021 ел Баулы шәһәре №100

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районының Административ
комиссиясе составына үзгәрешләр
кертү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2020 елның 19 ноябре редакциясендә) нигезендә, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 19 мартындагы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы административ комиссиясе турында» 36 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы административ комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- комиссия составыннан Осипова Азалия Салават кызын чыгарырга;

- комиссия составына кертергә:

комиссиянең җаваплы секретаре итеп билгеләп, Гөлнур Даниловна Маннанованы - Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитетының административ комиссиясе баш белгечен.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә алам.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы И.И. Хөснуллина